# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы
Әгер авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**11 ноябрь 2025 ел** **№1**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Тымытык авыл җирлеге Уставы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Тымытык авыл җирлеге Башлыгының "Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Тымытык авыл җирлеге Әгер торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында"27.10.2025 ел, № 3 карары нигезендә 2025 елның 11 ноябрендә узган Әгер авылы гражданнар җыены нәтиҗәләре белән Әгер авылы гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«Сез, 2026 елда Тымытык авыл җирлеге Әгер торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 400 сум күләмендә, 1 нче төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге формада белем алучы студентлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

-торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзекләндерү, ремонтлау, карап тоту (Җәлил, Совет, Тукай урамнары буйлап вак таш сатып алу, төяү, ташу, җәю)

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 57 кеше кертелгән, халык җыенында катнашып тавыш биргән гражданнар саны 46.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«РИЗА» позициясе өчен 43, «КАРШЫ» позициясе өчен 3 гражданнар җыенында катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Азнакай муниципаль районы Тымытык авыл җирлеге Әгер торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләре – гамәлдә (дөрес) дип танырга.

2. Түбәндәге сорау буенча карарны кабул ителгән дип танырга:
« Сез, 2026 елда Тымытык авыл җирлеге Әгер торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 400 сум күләмендә, 1 нче төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге формада белем алучы студентлардан, махсус хәрби операциядә

катнашучылардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:
-торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзекләндерү, ремонтлау, карап тоту (Җәлил, Совет, Тукай урамнары буйлап вак таш сатып алу, төяү, ташу, җәю)".

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Россия, Татарстан Республикасы, Азнакай районы, Тымытык авылы Тельман ур., 62Б нче йорт, Әгер авылы, Совет урамы, 27 йорт; адреслары буенча урнашкан мәгълүмат стендларына, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми сайтында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында http://aznakayevo.tatar.ru адресы буенча урнаштырып халыкка чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Тымытык авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Тымытык авыл жирлеге башлыгы Л.Р.Мостафина